СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район,
422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**« 20 » февраль 2020 ел** **№ 44**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге » муниципаль берәмлегенең Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (16.04.2019 ел, №23, 08.11.2019 ел, №39 номерлы үзгәрешләр белән)**

«Коррупциягә каршы көрәш турындагы Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге » муниципаль берәмлегенең Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (16.04.2019 ел, №23, 08.11.2019 ел, №39 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 11 статьяның 11.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерциячел яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу;

б) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиленнән алынган рөхсәт белән коммерциячел булмаган оешма белән түләүсез идарә итүдә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук